**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.10.2015 № 703

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 23 октябрендә теркәлде, № 2945

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә
радиация тәэсиренә дучар булган
гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга
ай саен бирелә торган
акчалата компенсация билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
"Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә
радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга
азык-төлек товарлары сатып алуга
ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын
раслау хакында" 16.07.2012, № 565 боерыгы белән
расланган административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында **боерык бирәм**:

1. Кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ

регламентын раслау хакында” 16.07.2012, № 565 боерыгы белән расланган “Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 05.10.2015 ел, № 703 боерыгына кушымта

**Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

1) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация тәэсиренә яки Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле бүтән авырулар алган яки кичергән гражданнар;

2) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар, түбәндәгеләр исәбенә керүчеләр:

аерып чыгарылучы зона чикләрендә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан яки Чернобыль АЭСын эшләтүдә яки башка эшләрдә мәшгуль булган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага килгән);

махсус җыеннарга чакырылган һәм Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләр башкаруга җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлылар (тупланган урыннарына һәм башкарган эшләренә бәйсез рәвештә), шулай ук аерып чыгарылучы зонада хезмәт иткән (итүче) эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте органнарының житәкчеләр һәм рядовойлар составы затлары;

эвакуацияләү турындагы карар кабул ителгәннән соң аерып чыгарылучы зонадан эвакуацияләнгән һәм күчереп утырту зонасыннан күчерелгән яисә әлеге зоналардан үз ихтыярлары белән чыгып киткән гражданнар;

сөяк җелеген күчереп утырту моментыннан алып узган вакытка һәм аларда моңа бәйле инвалидлык барлыкка килгән вакытка бәйсез рәвештә, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләрнең гомерен саклап калу өчен сөяк җелеген биргән гражданнар;

3) бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнар белән бергә яшәүче 14 яшькә җитмәгән балалар;

4) 1986-1987 елларда аерып чыгарылучы зона чикләрендә Чернобыль

һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә катнашкан яки бу чорда халыкны, матди байлыкларны, авыл хуҗалыгы хайваннарын эвакуацияләүгә бәйле эшләрдә һәм Чернобыль АЭСын эшләтүдә яки андагы башка эшләрдә мәшгуль булган гражданнар; махсус җыеннарга чакырылган һәм бу чорда аерып чыгарылучы зона чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләр башкаруга җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлылар, гражданнар авиациясенең очкыч-күтәрү, инженер-техник составын да кертеп (тупланган урыннарына һәм башкарган эшләренә бәйсез рәвештә); аерып чыгарылучы зонада 1986-1987 елларда хезмәт иткән эчке эшләр органнары җитәкчеләре һәм рядовойлары составы затлары; хәрби җыеннарга чакырылган һәм 1988-1990 елларда “Укрытие” объекты буенча эшләрдә катнашкан гражданнар, шул исәптән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлылар; 1986 елның 26 апреленнән 30 июненә кадәр чорда Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә зыян күргән һәм ионлаштыручы нурландыру чыганагы булып торган затларга медицина ярдәме һәм хезмәт күрсәткәндә нормадан артык нурланыш дозалары алган кече һәм урта медицина персоналы, табиблар һәм дәвалау учреждениеләренең башка хезмәткәрләре (эш урыннарында башкарылучы эш профиленә туры килүче радиация хәле шартларында һөнәри эшчәнлекләре ионлаштыручы нурландыру чыганакларының теләсә нинди төрләре белән эшләүгә бәйле затлардан гайре);

5) балалар, шул исәптән эвакуацияләү моментында ана карынында үсеш халәтендә булган балаларны да кертеп, 1986 елда аерып чыгарылучы зонадан эвакуацияләнгән (шул исәптән үз ихтыярлары белән чыгып киткән) гражданнар;

6) “Маяк” җитештерү берләшмәсендә 1957 нче елдагы авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1957-1958 елларда турыдан-туры катнашкан гражданнар, шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага килгән (махсус җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлыларны, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, гражданнар оборонасы органнарының җитәкчеләр һәм рядовойлар составы затларын да кертеп), шулай ук 1949-1956 елларда яклау чаралары һәм Тичә елгасы буендагы радиоактив пычранган территорияләрне тернәкләндерү уздыру эшләрендә мәшгуль булган гражданнар, махсус җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлыларны, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, гражданнар оборонасы органнарының җитәкчеләр һәм рядовойлар составы затларын да кертеп;

7) “Маяк” җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ләгү аркасында радиация тәэсире нәтиҗәсенә дучар булган торак пунктлардан эвакуацияләнгән (күчерелгән) (шул исәптән эвакуацияләү (күчерү) өлешчә башкарылган торак пунктлар чикләрендә эвакуацияләгәннәр (күчерелгәннәр)), шулай ук үз ихтыярлары белән чыгып киткән гражданнар, балаларны шул исәптән эвакуацияләү (күчерү) моментында ана карынындагы үсеш халәтендә булган балаларны да кертеп, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби хезмәткәрләр, гаскәри частьларның үз ихтыяры белән ялланганнар составы һәм махсус контингент. Үз ихтыярлары белән чыгып киткән гражданнарга “Маяк” җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария нәтиҗәсендә радиоактив пычрануга дучар

булган торак пунктлардан 1957 елның 29 сентябреннән 1960 елның 31 декабренә кадәр (кертеп) чыгып киткән, шулай ук Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктлардан 1949 елдан 1962 елга кадәр (кертеп) чыгып киткән (шул исәптән күчерү өлешчә башкарылган торак пунктлар чикләрендә күчеп утырган) гражданнар керә;

8) № 175-ФЗ Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбенә керүче, нурланыш авыруы, барлыкка килүләре яки көчәюләре "Маяк" җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәсендә радиация тәэсире аркасында булган авырулар исемлегенә кертелгән бүтән авырулар алган гражданнар;

9) № 175-ФЗ Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбенә керүче, "Маяк" җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәсендәге инвалидлар;

10) бу пунктның 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар белән бергә яшәүче 14 яшькә җитмәгән балалар;

11) № 2123-1 карарның 1 статьясындагы "а" – "г" пунктларында күрсәтелгән аеруча куркыныч подразделениеләрдә булган гражданнар;

12) № 2123-1 карарның 1 статьясында күрсәтелгән аеруча куркыныч подразделениеләрдә булып, инвалидка әверелгән гражданнар;

13) түбәндәгеләр белән бергә яшәүче 14 яшькә җитмәгән балалар:

№ 2123-1 карарның 1 статьясындагы "а" – "г" пунктларында күрсәтелгән аеруча куркыныч подразделениеләрдә булган гражданнар; № 2123-1 карарның 1 статьясында күрсәтелгән аеруча куркыныч подразделениеләрдә булып, инвалидка әверелгән гражданнар;

14) Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән нурланыш авыруы һәм бүтән авырулар аркасында үлгән гражданнар исәбенә керүче туендыручысын югалткан гаиләләр, шулай ук аларга № 1244-1 РФ законының 14 статьясында күрсәтелгән социаль яклау чаралары кагыла торган үлгән инвалидлар гаиләләре;

15) "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендәге инвалидлар һәм нурланыш авыруы, барлыкка килүләре яки көчәюләре "Маяк" җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәсендә радиация тәэсире аркасында булган авырулар исемлегенә кертелгән бүтән авырулар алган гражданнар исәбенә керүче туендыручысын югалткан гаиләләр, үлемнәре "Маяк" җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында булган очракта;

16) аеруча куркыныч подразделениеләрдә булган гражданнар исәбенә керүче туендыручысын югалткан гаиләләр;

17) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге авырулар яки ата-аналарының берсенең радиоактив нурланыш алуы генетик нәтиҗәләре аркасында килеп чыккан авырулардан интегүче балалар һәм яшүсмерләр;

18) № 175-ФЗ Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбенә керүче ата-аналарына радиация тәэсире булу аркасында авырулардан

интегүче беренче һәм икенче буын балалары;

19) 1949-1963 елларда Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтәге, Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланучы исемлекләренә кертелгән торак пунктларда яшәгән, нурланышның 25 сЗв (бэр)дан артып киткән суммар (тупланма) эффектив дозасын алган гражданнар.

Бу пунктта күрсәтелгән, радиация тәэсиренә дучар булып, хәзерге вакытта хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнары, җинаять-башкару системасы, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәт учреждениеләре һәм органнары, наркотик матдәләр һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тотучы органнар, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләре, бу затлар исәбенә керүче, шул исәптән эшләүче (эш урынына бәйсез рәвештә) пенсионерлар, башкарма хакимиятнең әлеге федераль органнарының гражданлык персоналы булып торучы, шулай ук салым полициясе органнарыннан эштән азат ителгән затлар исәбенә керүче, шул исәптән эшләүче (эш урынына бәйсез рәвештә) пенсионерлар булып торучы гражданнар категорияләре исәбендәге затлар дәүләт хезмәте алучыларга керми.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (закон белән күздә тотылган очракларда) яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә күрсәтелә.

1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы: Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнүче эш сәгатьләрендә шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык), Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Регламентның 1.1, 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz@tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http:// uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка (http://mtsz@tatar.ru) язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Идарә (бүлек) биналарындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” 15 май, 1991 ел, № 1244-1 Россия Федерациясе законы (алга таба – № 1244-1 РФ законы) (РСФСРның Халык депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 21, 699 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Гражданлык хәле актлары турында” 15 ноябрь, 1997 ел, № 143-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 143-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“1957 елда “Маяк”җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында” 26 ноябрь, 1998 ел, № 175-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 175-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 1998, № 48, 5850 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында” 10.01.2002 ел, № 2-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 2-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 2002, № 2, 128 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 7 май, 2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

30.11.1994 ел, № 51-ФЗ Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (беренче өлеш) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” РСФСР Законының гамәлдә булуының аеруча хәтәр подразделениеләрдә булган гражданнарга кагылуы турында” 27.12.1991 ел, № 2123-1 Россия Федерациясе Югары Советы карары (алга таба – № 2123-1 РФ ЮС карары) (РСФСРның Халык депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы хәбәрләре, 1992, № 4, 138 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация бирүнең “Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” 31.12.2004 ел, № 907 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган кагыйдәләре (алга таба – 1 Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 2, 164 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация бирүнең 30.12.2004 ел, № 882 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган кагыйдәләре (алга таба – 2 Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 2, 151 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Зыянны каплау һәм гражданнарга “Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” Россия Федерациясе законы, “1957 елда “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында” Федераль закон һәм “Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында” Федераль закон белән күздә тотылган социаль яклау чаралары бирү буенча Россия Федерациясенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 августындагы № 542 карары белән расланган кагыйдәләре (РФ законнары җыентыгы, 2005, № 36, 3707 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидияләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында” 22.01.2005 ел, № 20 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2005, № 5, 0156 ст.) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 388 ТР МК карары)

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 05.09.2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү “тәрәзә”се.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

**2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү | № 1244-1 РФ законының 14 ст. 1 өл. 13 п., 15 ст. 1 өл. 3 п. ;<br>1 Кагыйдәләрнең 1 п.;<br>2 Кагыйдәләрнең 1 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) | 1 Кагыйдәләрнең 2 п.;<br>2 Кагыйдәләрнең 3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кергәннән соң биш эш көне эчендә хәл ителә (ведомствоара үзара хезмәттәшлек каналлары аша запрос җибәрү кирәк булмаган очракта).<br>Ведомствоара үзара хезмәттәшлек каналлары аша документлар сорау зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү срогы ун эш көненә кадәр озайтыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, | 1. Компенсация билгеләү турында гариза (почта адресын яки дәүләт хезмәте алучы тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп) (бу Регламентка 1 нче кушымта). Дәүләт хезмәте алучыга акча күчерү өчен, опекун (химаяче) югарыда әйтелгән кредит оешмасында үзе ачкан номиналь счетның реквизитларын күрсәтә.<br>2. Социаль ярдәм чараларына хокук бирүче таныклык күчермәсе.<br>Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар, өстәмә рәвештә, аерып чыгарылучы зонадан чыгып китү | 1 Кагыйдәләрнең 2 п.;<br>2 Кагыйдәләрнең 3 п. |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | фактын раслаучы белешмә тапшыралар.<br>Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 14, 15, 1 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар, өстәмә рәвештә, туендыручының үлеменә китергән авыруның радиация факторлары нәтиҗәләре белән сәбәпле бәйләнештә булуын билгеләү турында ведомствоара экспертлар советының (хәрби табиблар комиссиясенең) йомгаклау нәтиҗәсе күчермәсен тапшыралар.<br>Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 3, 10, 13 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар, өстәмә рәвештә, ата-аналарының берсенең яисә әбисенең, бабасының, опекунның бала белән бергә яшәве турында яшәү урыныннан белешмә күчермәсен тапшыралар.<br>Опекун (химаяче), санап кителгән документларга өстәп, балага опека (химаячелек) билгеләнү турында җирле үзидарә органы карарын тапшыра.<br>Дәүләт хезмәте алучы Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнарда күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документлар тапшыра.<br>Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.<br>Документлар күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге мәгълүматларны раслаучы документлар алына:<br>балалар тууны дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);<br>никахка керүне дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан сорала);<br>туендыручының үлүе турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан сорала);<br>Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан пенсия алу факты турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан). | |

| | | |
|---|---|---|
| аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар кергән документлар тапшыруга хокуклы, шул исәптән, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә. Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматлар кергән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләренә туры китереп электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон | |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар рәвешендә тапшыру.<br>3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.<br>4. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте алучы яшәмәгән урындагы Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.<br>5. Бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып, ялган (дөреслеккә туры килмәгән) мәгълүматлар кергән документлар тапшыру тора. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтү) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | № 601 РФ Президенты Указының 1 п. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен, шул исәптән | Гариза һәм документлар кергән көнне. | |

| | | |
|---|---|---|
| электрон рәвештә, теркәү срогы | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырылган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән һәм:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>- Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>- мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>- гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>- документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>- белгечләр тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) | № 880 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.;<br>№ 601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz@tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль закон;<br>№ 210-ФЗ Федераль закон |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) компенсация билгеләүгә гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

4) компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны әзерләү һәм кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

6) техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 2 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, почта, электрон почта аша, шул исәптән техник мөмкинлек булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, почта, электрон почта аша һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша гариза бирүчегә консультация үткәрә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, гариза бланкын бирә, зарурлык булганда гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан искәртмәләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны

рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Компенсация билгеләүгә гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту

3.3.1. Гариза бирүче, Идарәгә (бүлеккә) компенсация билгеләү турында гариза һәм аңа кушып, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә, документлар күчермәләрен бирә.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә расланган кушып бирелүче күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) документлар (документлар күчермәләре) электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Почта аша яки электрон документ рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) 3.3 пункт белән күздә тотылган тәртиптә карап тикшерелә.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

законлы вәкил сыйфатында эш итүче гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен (документларның тиешенчә рәсмиләштерелгәнлеген, документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм алдан ук әйтелмәгән башка төзәтүләр булу-булмавын) тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече документларны кабул итүдән баш тартуның ачыкланган нигезләренең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә документларын кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра; гариза почта, шул исәптән электрон почта аша җибәрелгәндә, документларны кабул итү датасы турында хәбәр итү язуын почта, шул исәптән электрон почта аша җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы булдыру, расписка яки документларны кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә язмача хәбәр итү һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече, электрон рәвештә, түбәндәге мәгълүматларны ала:

дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләнү турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан);

балалар тууны дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);

никахка керүне дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);

туендыручының үлүе турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан).

3.4.2. Идарәдә (бүлектә) компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Идарә (бүлек) белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, электрон рәвештә, түбәндәге мәгълүматларны бирүне сорап, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләнү турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына);

балалар тууны дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарына);

никахка керүне дәүләт теркәве турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарына);

туендыручының үлүе турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарына).

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган мәгълүматлар, мәгълүматлар бирү хакында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5. Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны әзерләү һәм кабул итү

Бу Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән алынган мәгълүматлар һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында бу Регламентка 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча карар проектын рәсмиләштерә;

карар проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән көннән башлап ике эш көне эчендә үтәлә. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорап алу зарурлыгы булганда – рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән моменттан ике эш көне эчендә, ләкин гариза теркәлгән көннән башлап җиде эш көненнән дә соңармыйча.

Процедуралар нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проекты.

3.5.2. Документларны карап тикшергәннән соң, Идарә (бүлек) җитәкчесе

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедура документларны компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын имзалауга җибәргән моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Идарә (бүлек) белгече:

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында, гаризада күрсәтелгән ысул (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта) белән, гариза бирүчегә хәбәр итә;

билгеләү турында карар кабул ителгән очракта, гариза бирүченең “личное дело”сын рәсмиләштерә (барлык документларны бер папкага туплый).

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү, гариза бирүченең рәсмиләштерелгән “личное дело”сы (уңай карар кабул ителгән очракта).

3.7. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

3.8. Техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) төзәтү

Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ өстәлгән (әгәр андый документ бирелгән булса) теркәлгән гариза (киңәш ителүче форма бу Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән) нигезендә башкарыла.

3.8.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында (бу Регламентка 3 нче кушымта) терки;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан бер эш

көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турындагы кабул ителгән, теркәлгән гариза, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән карар проекты.

3.8.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура карар проекты имза куюга җибәрелгән моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән имзаланган карар.

3.8.3. Идарә (бүлек) белгече компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны, гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районндагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) вазыйфаи затлары башкара. Контрольлек итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре Идарә (бүлек) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатькә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып:

делопроизводствоны алып баруга;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүенә;

документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә тикшерүләр үткәрү тора.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә) һәм планнан тыш (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.2. Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр тәртиптә Идарә (бүлек) җитәкчесенә шикаять белдерүгә хокуклы.

Идарә (бүлек) җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка шуның белән шөгыльләнүче министр урынбасары яки министр исеменә бирелә.

Министр урынбасары (министр) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән

Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерелү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә атамасы, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт

хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсе (бүлеге) начальнигына

ГАРИЗА

№ _____ "_________" ____________20______ел

Мин, ______________________________________________________________,

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшим:

_______________________________________________________________

(гариза бирүченең почта адресы, индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп)

| Гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелүе | Бирелү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Түбәндәге документ нигезендә эш итәм: ___________________________________

_______________________________________________________________

(гариза бирүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ реквизитлары)

1. "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" 15 май, 1991 ел, № 1244-1 Россия Федерациясе законына;

"1957 елда "Маяк"җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" 26 ноябрь, 1998 ел, № 175-ФЗ Федераль законга;

"Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында" 10.01.2002 ел, № 2-ФЗ Федераль законга;

"Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" РСФСР Законының гамәлдә

булуының аеруча хәтәр подразделениеләрдә булган гражданнарга кагылуы турында" 27.12.1991 ел, № 2123-1 Россия Федерациясе Югары Советы карарына

(кирәклесенең астына сызарга)

туры китереп, ________________________________________________ га (гә)

(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләвегезне үтенәм.

2. Билгеләнгән түләүне күчерергә:
счет реквизитлары

________________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучы яки аның законлы вәкиле тарафыннан, законда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары күрсәтелә.

почта бүлеге реквизитлары ________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының яки аның законлы вәкиленең почта бүлеге реквизитлары күрсәтелә)

Гаризага кушып, түбәндәге документларны (күчермәләрне) һәм белешмәләрне тапшырам:

| Т-п № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

3. Тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җаваплылыкны үз өстемә алам. Түләүләрне туктатуга (үзгәртүгә) сәбәп булырлык шартлар туу турында үз вакытында хәбәр итү йөкләмәсе турындагы нигезләмә белән таныштым.
4. 2006 елның 27 июлендәге "Персональ мәгълүматлар турында" № 152-ФЗ Федераль законга нигезләнеп, бу Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртүгә, саклауга һәм персональ мәгълүматны алмашу системасындагы өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм:

________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының, шулай ук гариза дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен яклаучы зат тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүченең Ф.И.О. күрсәтелә)

________________________________.

(гариза бирүченең имзасы)

Гариза бирүче:

________________________ ____________ "__" ________ 20__ел

(дәүләт хезмәте алучының, гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә расланган ышанычнамә нигезендә яклаучы затның Ф.И.О.) (имза)

5. Мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) ________________________ алырга риза.

(язмача, телефоннан, смс-хәбәр итеп, электрон почта белән)

“__” ________ 20__ ел Имза ______________

Гариза һәм документлар кабул ителде ___ 20__ел ______ __________________

(белгеч имзасы, тулы имза)

---

*Өзеп алу сызыгы*

Расписка-хәбәрнамә

Гариза бирүчене теркәү номеры


Документлар саны ___ берәмл. ___ биттә

Документларны кабул итте________ ______ ___________ ________20____ел

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гаризаларны теркәү

**ЖУРНАЛЫ**

| Т-п № | Гариза бирү көне | Гариза-ның но-меры | Гражданинның ФИО | Адрес | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗә-гатьнең нәтиҗә-ләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

___________________________________
(муниципаль районндагы яки шәһәр округындагы)
Социаль яклау идарәсе (бүлеге)

"_____" ____________ № ________

**Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар**

1. Фамилия, исем, атасының исеме ________________________________________
2. Туган елы ____________________________________________________________
3. Яшәү урыны адресы __________________________________________________
4. Алучының категориясе ________________________________________________
5. Компенсацияне түбәндәгеләргә туры китереп билгеләргә:

"Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" 15 май, 1991 ел, № 1244-1 Россия Федерациясе законына:

____ сум ____ тиен күләмендә ______ дан _____ га кадәр чорга;

"1957 елда "Маяк"җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" 26 ноябрь, 1998 ел, № 175-ФЗ Федераль законга:

____ сум ____ тиен күләмендә дан _____ га кадәр чорга;

"Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында" 10.01.2002 ел, № 2-ФЗ Федераль законга:

____ сум ____ тиен күләмендә дан _____ га кадәр чорга;

"Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" РСФСР Законының гамәлдә булуының аеруча хәтәр подразделениеләрдә булган гражданнарга кагылуы турында" 27.12.1991 ел, № 2123-1 Россия Федерациясе Югары Советы карарына:

____ сум ____ тиен күләмендә дан _____ га кадәр чорга;
(кирәклесенең астына сызарга)

6. Яңадан исәпләү: ______________________________________________
7. Компенсация өчен мөрәҗәгать итү көне ___________________________
8. Компенсация билгеләүдән баш тартырга ___________________________
_________________________________________________________________

Социаль яклау идарәсе (бүлеге)
начальнигы ________________________________
(имза) (тулы имза)

Белгеч ________________________________
(имза) (тулы имза)

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________
муниципаль райондагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсе (бүлеге) начальнигына

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Мин,____________________________________________________________________,
*(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*
түбәндәге адрес буенча яшим: _____________________________________________
________________________________________________________________________
*(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)*
________________________________________________________________________
*(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне,*
________________________________________________________________________,
*документны биргән орган атамасы)*

Социаль ярдәм чараларын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы
_______________ № _______________
*карар датасы* *карар номеры*
карарда җибәрелгән техник хатаны ____________________________________
төзәтүне үтенәм.
Техник хатаның төзәтелүе турында мәгълүматны
__________________________________________________ алырга риза.
(язмача, телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта белән)

“__” ________ 20__ ел Имза _______________

“__” ________ 20__ ел _____________ ______________________________
(гариза бирүче имзасы) (тулы имза)

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен бирелә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы яки шәһәр округларындагы Социаль яклау идарәләре (бүлекләре)

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>К.Маркс ур., 8 й.<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423330, Азнакай ш.,<br>Болгар ур., 9 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-73-68<br>2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б.,<br>Ленин ур., 8 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45 й.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б.,<br>Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав.,<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8553)<br>32-45-50 | 423452, Әлмәт ш.,<br>8 Март ур., 21а й.<br>Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-11-84<br>2-10-81 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш.,<br>Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш.,<br>Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78 | 422250, Балтач ав.,<br>Һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85594)<br>4-20-05<br>4-26-64 | 423231, Бөгелмә ш.,<br>Совет ур., 56 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43 | 422700, Биектау т/ю ст. б.,<br>Профсоюзлар ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-51-55<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.;<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>3-43-59 | 423520, Зәй ш.,<br>Крупская ур, 6 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-79-90 | 420540, Зеленодол ш.,<br>Ленин ур., 25 й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>Карл Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.,<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.т.б., Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендәге Социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>проспект Х.Туфана, д. 23<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык пр., 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423042, Нурлат ш.,<br>Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
| --- | --- | --- |
| Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84361) 2-11-57 2-39-62 | 422650, Балык Бистәсе ав., Завод ур., 6а й. Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84362) 2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ав., Тукай ур., 87 й. Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85559) 2-45-72 2-49-87 | 423350, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й. Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84347) 3-08-81 3-00-00 3-08-98 | 422864, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 13 й. Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84373) 2-62-31 | 422370, Тәтеш ш., Ленин ур., 114 й. Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (8552) 70-00-57 | 423807, Чаллы ш., М.Җәлил проспекты, 46 й. Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84360) 2-13-41 | 422080, Теләче ав., Большая Нагорная ур., 5 й. Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84396) 2-57-05 2-50-94 | 423100, Чирмешән ав., Гагарин ур, 7 й. Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84342) 5-55-73 5-11-50 | 422980, Чистай ш., Урицкий ур., 45 й. Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85593) 2-21-43 2-82-91 2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 105/1 й. Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш районындагы Социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036, Казан ш., Тимирязев ур., 8 й. Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов районындагы Социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420197, Казан ш., Вишневский ур., 10 й. Usz.Vahit@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров районындагы Социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.; Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Мәскәү районындагы Социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095, Казан ш., Блюхер ур., 81а й. Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районындагы Социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420124, Казан ш., Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й. Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Идел буе районындагы Социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420110, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й. Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районындагы Социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420073, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.; Usz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Bytaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Бирелүче социаль ярдәм чараларының функциональ аудиты бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппаратының Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |